**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. №57 "13" ноябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2012 елның 17 октябрендәге 34 номерлы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карары хакында (30.09.2013 № 26, 17.06.2014 № 24, 19.09.2014 № 36, 05.09.2017 №15 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чиста һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатларында,

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2012 елның 17 октябрендәге 34 номерлы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карары хакында (30.09.2013 № 26, 17.06.2014 № 24, 19.09.2014 № 36, 05.09.2017 №15 карарлар редакциясендә) карар кушымтасында бирелгән проектны хупларга.

3. Билгеләргә:

- 2018 елның 26 ноябреннән 2018 елның 28 декабренә кадәр уздыру вакыты;

- үткәрелү урыны - Актүбә ш.т.п., Губкин ур. 24;

- 2018 елның 28 декабренә кадәр - Актүбә ш.т.п. буенча язма тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертелергә мөмкин булган адрес: Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр (төшке ашка тәнәфес 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

4. Катнашкан гавами тыңлаулар уздыру буенча эш төркемен төзергә:

- Галиева Роза Алмас кызы - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы;

- Газизов Илтозар Илдус улы - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 5 нче округ депутаты;

- Садыйков Руслан Рамил улы - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 6 нчы округ депутаты.

5. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы (30.09.2013 № 26, 17.06.2014 №24, 19.09.2014 №36, 05.09.2017 №15 карарлар редакциясендә) карар проекты буенча халык алдында тыңлаулар уздыруны тәэмин итү.

6. Торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссия гавами тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, чираттагы утырышны карауга кертергә тиеш.

7. Әлеге карарны, 2018 елның 19 апреленнән дә соңга калмыйча, түбәндәге веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo. tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының түбәндәге веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://aznakayevo. tatar.ru.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Р.А. Галиев

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы 2018 елның "13" ноябреннән №57 карарына кушымта

**ПРОЕКТ**

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. № ____ "_____" _____________2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 463-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм тулаем Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү объектларын чиста һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатларында,

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2012 елның 17 октябрендәге 34 номерлы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карары хакында (30.09.2013 № 26, 17.06.2014 № 24, 19.09.2014 № 36, 05.09.2017 №15 карарлар редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының икенче, өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян

итәргә:

«Территорияне төзекләндерү - гражданнарның яшәү шартларының уңайлылыгын тәэмин итүгә һәм арттыруга, муниципаль берәмлек территориясенең санитария һәм эстетик торышын яхшыртуга, торак пунктлар территорияләрен һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, корылмаларны, якын территорияләрне карап тотуга юнәлдерелгән әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру эшчәнлеге.

Төзекләндерү элементлары - территорияне төзекләндерүнең состав өлеше буларак кулланыла торган декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, җиһазларның һәм бизәлешнең төрле төрләре, шул исәптән биналарның, корылмаларның фасадлары, кече архитектура формалары, конвертсыз төзелеш һәм корылмалар, мәгълүмати щитлар һәм күрсәткечләр. "

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 2.10.3.1 пункт өстәргә:

«2.10.3.1. Йорт билгеләрендәге, тышкы мәгълүмат чараларындагы мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнар таләпләрен үтәгән килеш урнаштырылырга тиеш. Ике яки аннан да күбрәк тел кулланган очракта, текстлар эчтәлек һәм техник бизәлеш буенча тиңдәш булырга, грамоталы һәм аңлаешлы итеп башкарылырга тиеш. "

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы поселогы Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.